Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № II-6**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 6 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында төп эш урыны буенча эшләүче гражданнарга түләүсез файдалануга җир кишәрлекләре бирү тәртибе турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 маддәсендәге 2 пунктының 7 пунктчасы, Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында төп эш урыны буенча эшләүче гражданнарга түләүсез файдалануга җир кишәрлекләре бирү тәртибе турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга (алга таба – Нигезләмә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Ф.М.Вафинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының 2020 елның
6 октябрендәге II-6 номерлы
карары белән
расланды

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында
төп эш урыны буенча эшләүче гражданнарга түләүсез файдалануга
җир кишәрлекләре бирү тәртибе турында
Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге милкендәге җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында төп эш урыны буенча Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 маддәсендә билгеләнгән оешмаларда эшләүче гражданнарга индивидуаль торак төзелеше яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен файдалануга бирү тәртибен җайга сала.

1.2. Җир кишәрлекләрен бирү Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.3. Әлеге карарның максатлары булып авыл территорияләрен үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне, эшкәртүне һәм сатуны арттыру өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен тарту, шулай ук Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә эшләргә белгечләрне җәлеп итү тора.

1.4. "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге милкендә булган җир кишәрлекләре һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.5. Җир кишәрлекләрен алга таба түләүсез файдалануга бирү өчен формалаштыру һәм түләүсез файдалануга шартнамәләр төзү мөрәҗәгать итүчеләр акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

1.6. Әлеге Нигезләмә "Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2016 елның 7 маендагы 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергәннән (2016 елның 17 маеннан) соң төп эш урынына кергән затларга кагыла.

**2. Төп эш урыны буенча Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районында эшләүче гражданнарга**
**түләүсез файдалануга җир кишәрлекләре бирү шартлары**

2.1. "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге милкендәге җир кишәрлекләре һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре бер мәртәбә, әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән шартлар бер

үк вакытта булганда, гражданнарга индивидуаль торак төзелеше яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен алты елдан артык булмаган вакытка түләүсез файдалануга бирелә.

2.2. Җир кишәрлекләре гариза биргән датага бер үк вакытта түбәндәге шартларга җавап бирә торган затларга бирелә:

2.2.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче шәһәр яки авыл җирлекләрендә төп эш урыны буенча түбәндәге оешмалар төркемнәренең берсендә эшлиләр:

1) мәгариф оешмаларында “педагогик белем бирү”, “мәктәпкәчә белем бирү”, “башлангыч сыйныфларда белем бирү”, “өстәмә белем бирү педагогикасы” белгечлекләре буенча;

2) медицина оешмаларында “дәвалау эше”, “акушерлык эше”, “шәфкать туташы эше” белгечлекләре буенча;

3) авыл хуҗалыгы оешмаларында "агрономия", "ветеринария", "зоотехния", "агроинженерия", "авыл хуҗалыгын механикалаштыру" белгечлекләре буенча.

2.2.2. Татарстан Республикасының Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә затның үз милкендә җир кишәрлеге юк.

## 3. Төп эш урыны буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында эшләүче гражданнарга түләүсез файдалануга җир кишәрлекләре бирү тәртибе

3.1. Гражданнар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турындагы яисә бирү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итә.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлергә тиеш:

1) Мөрәҗәгать итүче паспортының барлык битләренең күчермәләре (чагыштыру өчен төп нөсхә).

2) Эш урыны буенча таныкланган эшкә алу турында боерык күчермәсе һәм хезмәт кенәгәсеннән өземтә күчермәсе.

3) Соралган җир кишәрлеген төзергә кирәк булып, чикләрендә мондый җир кишәрлеген төзү көтелгән территорияне ызанлау проекты булмаган очракта, җир кишәрлегенең урнашу схемасы.

4) Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, әгәр җир кишәрлеген алдан килештерү яисә бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итүченең вәкиле мөрәҗәгать итсә.

5) "Дәвалау эше", "акушерлык эше", "шәфкать туташы эше" белгечлекләре буенча Нигезләмәнең 3.1 пунктының 1, 2 пунктчаларында күрсәтелгән документлардан тыш – РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2012 елның 29 сентябрендәге 982нче номерлы боерыгы нигезендә бирелгән белгеч сертификаты күчермәсе (чагыштыру өчен төп нөсхә).

3.2 Мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшырырга хокуклы:

1) югары яисә урта һөнәри белем турында диплом күчермәсен;

2) граждан эшли торган мәгариф, медицина, авыл хуҗалыгы учреждениесе (оешмасы) җитәкчесенең шәхси торак төзелеше яки шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару

өчен аңа түләүсез файдалануга җир кишәрлеге бирү турындагы үтенечнамәсен (юллавын);

3) күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир кишәрлеге турында) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтәне;

4) күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан аның элек булган (хәзер бар булган) күчемсез милек объектларына хокуклары турында өземтәне (ягъни мөрәҗәгать итүченең рөхсәт ителгән файдалану төрләре булган җир кишәрлекләренә хокуклары турында – шәхси торак төзелеше яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен).

Әгәр күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмаган булса, алар вәкаләтле орган тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек ярдәмендә яисә язма гарызнамә юлы белән алынырга тиеш.

3.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына кергән документлар белән гариза Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында төп эш урыны буенча эшләүче гражданнарның түләүсез файдалануга җир кишәрлекләре бирү турында мөрәҗәгатьләрен исәпкә алу журналында теркәлә (1 нче кушымта).

3.4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы гариза кергән көннән 30 көннән дә артмаган вакыт эчендә гариза бирүчегә җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану турында шартнамә әзерли һәм бирә.

3.5. Граждан җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану шартнамәсе Россия Федерациясе Җир кодексында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда төзелә.

3.6. Мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты таләпләренә туры килми торган документларны тапшырганда, әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында каралган шартларны үтәмәгәндә, алар, кире кайтару сәбәпләрен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарыла.

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән шартнамәләр проектлары имзаланырга һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән шартнамәләр проектларын алган көннән алып утыз көннән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.

3.8. Граждан мондый җир кишәрлеген күрсәтелгән чорда билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану нигезендә файдаланган очракта, анда рөхсәт документлары нигезендә объект төзегән һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән белгечлек буенча төп эш урыны буенча эшләгәндә җир кишәрлеге түләүсез файдалануга бирелгән көннән соң алты ел узгач, җир кишәрлеге аның үз милкенә түләүсез бирелергә мөмкин.

3.9. Граждан әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында билгеләнгән шартларны үтәмәгән очракта, бирелгән җир кишәрлеге алынырга һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә гавами торгиларда сатылырга (реализацияләнергә) тиеш.

3.10 Граждан тарафыннан мәгариф, медицина, авыл хуҗалыгы оешмасы белән хезмәт шартнамәсе туктатылган очракта, җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү датасыннан алып алты ел вакыт узганчы, белгеч җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану хокукын югалта. Күчемсез милек объекты астындагы җир кишәрлеге мондый очракта Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3, 39.6, 39.20 маддәләрендә

билгеләнгән тәртиптә бирелергә мөмкин. Түләүсез файдалану хокукы югалган һәм анда күчемсез милек объекты булмаган очракта, җир кишәрлеге Россия Федерациясе Җир кодексында каралган тәртиптә алынырга һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә гавами торгиларда сатылырга (реализацияләнергә) тиеш.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районында
төп эш урыны буенча эшләүче гражданнарга
түләүсез файдалануга
җир кишәрлекләре бирү тәртибе турындагы
Нигезләмәгә 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында төп эш урыны буенча эшләүче гражданнарның җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү турында мөрәҗәгатьләрен исәпкә алу журналы

| № п/п | Исәпкә кую өчен гариза бирү датасы | Мөрәҗә-гать итүченең фамилия-се, исеме, атасының исеме | Мөрәҗәгать итүченең теркәлү урыны | Тапшырылган документлар исемлеге һәм реквизитлары | Җир кишәрлеге ирү турында тамга (карарның номеры һәм датасы) | Искәрмә |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| | | | | | | |